**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# О совершенствовании системы поддержки новых инвестиционных проектов в Республике Татарстан

В целях повышения инвестиционной привлекательности Республики Татарстан, с учетом положений приказа Министерства экономического развития Российской Федерации от 30 сентября 2021 года № 591 «О системе поддержки новых инвестиционных проектов в субъектах Российской Федерации («Региональный инвестиционный стандарт»)» **постановляю**:

1. Утвердить прилагаемое Положение о кураторе инвестиционного проекта, реализуемого на территории Республики Татарстан.

2. Агентству инвестиционного развития Республики Татарстан:

совместно с Министерством земельных и имущественных отношений Республики Татарстан, Министерством промышленности и торговли Республики Татарстан, Министерством строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан, Министерством транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан обеспечить ежегодную актуализацию алгоритмов действий («клиентских путей») инвестора, планирующего реализацию инвестиционного проекта на территории Республики Татарстан, с учетом положений Методических рекомендаций по внедрению Свода инвестиционных правил субъекта Российской Федерации, утвержденных приказом Министерства экономического развития Российской Федерации от 30 сентября 2021 года № 591 «О системе поддержки новых инвестиционных проектов в субъектах Российской Федерации («Региональный инвестиционный стандарт»)»;

разработать и внести на утверждение в Кабинет Министров Республики Татарстан порядок формирования механизма обратной связи с субъектами инвестиционной и предпринимательской деятельности в Республике Татарстан;

установить порядок разработки и утверждения плана мероприятий («дорожной карты») по реализации инвестиционного проекта, рассмотренного Инвестиционным советом Республики Татарстан.

3. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 5 июля 2012 года № УП-538 «Об образовании Инвестиционного совета Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан

от 6 сентября 2012 года № УП-745, от 3 ноября 2012 года № УП-914, от 20 марта 2013 года № УП-242, от 29 марта 2013 года № УП-258, от 8 августа 2013 года № УП-717, от 29 апреля 2014 года № УП-440, от 27 августа 2014 года № УП-826, от 2 марта 2015 года № УП-199, от 13 октября 2015 года № УП-984, от 29 июня 2016 года № УП-553, от 8 июня 2017 года № УП-480, от 4 сентября 2018 года № УП-612, от 8 февраля 2019 года № УП-90, от 12 октября 2019 года № УП-619, от 28 марта 2020 года № УП-206, от 26 ноября 2020 года № УП-782, от 23 декабря 2021 года № УП-990, от 11 августа 2022 года № УП-542, указами Раиса Республики Татарстан от 13 марта 2023 года № 150, от 9 сентября 2023 года № 631 и от 28 ноября 2023 года № 813) следующие изменения:

а) абзац второй пункта 3 Положения об Инвестиционном совете Республики Татарстан изложить в следующей редакции:

«рассмотрение и анализ инвестиционных проектов на предмет целесообразности их реализации на территории Республики Татарстан и необходимости (возможности) их софинансирования за счет средств бюджета Республики Татарстан, местных бюджетов, а также определение куратора инвестиционного проекта, реализуемого на территории Республики Татарстан;»;

б) в составе Инвестиционного совета Республики Татарстан (далее – Инвестиционный совет):

вывести из состава Инвестиционного совета Ф.А. Аглиуллина, А.Ю. Егорова;

ввести в состав Инвестиционного совета:

Абдулхакова Рустама Рифгатовича – директора муниципального унитарного предприятия города Казани «Водоканал» (по согласованию);

Кадырова Азата Рифгатовича – министра земельных и имущественных отношений Республики Татарстан.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
14 августа 2024 года
№ 620

Утверждено
Указом Раиса
Республики Татарстан

от «14» августа 2024 года
№ 620

**Положение**
**о кураторе инвестиционного проекта, реализуемого на территории Республики Татарстан**

1. Настоящее Положение устанавливает порядок определения куратора инвестиционного проекта, реализуемого на территории Республики Татарстан (далее соответственно – куратор, инвестиционный проект), правовое положение куратора и его основные задачи.

2. Куратор определяется решением Инвестиционного совета Республики Татарстан из числа руководителей республиканских органов исполнительной власти или глав муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан, на территории которых реализуется инвестиционный проект, по согласованию с указанными должностными лицами.

3. Основными задачами куратора являются:

а) разработка плана мероприятий («дорожной карты») по реализации инвестиционного проекта совместно с Агентством инвестиционного развития Республики Татарстан, субъектом инвестиционной деятельности, реализующим инвестиционный проект, иными лицами, участвующими в реализации инвестиционного проекта, и представление его для утверждения в Агентство инвестиционного развития Республики Татарстан;

б) мониторинг реализации инвестиционного проекта;

в) ежеквартальное информирование секретаря Инвестиционного совета Республики Татарстан о ходе реализации инвестиционного проекта.

4. В целях реализации инвестиционного проекта куратор имеет право проводить совещания с представителями Агентства инвестиционного развития Республики Татарстан, субъекта инвестиционной деятельности, реализующего инвестиционный проект, и иными лицами, участвующими в реализации инвестиционного проекта, для разрешения спорных ситуаций, возникающих при реализации инвестиционного проекта.

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасын камилләштерү турында**

Татарстан Республикасының инвестицияләр кертүгә кызыксындыру дәрәҗәсен арттыру максатларында, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм күрсәтү системасы («Төбәк инвестиция стандарты») турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы нигезләмәләрен исәпкә алып **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция проекты кураторы турында нигезләмәне (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгына:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашырырга планлаштыручы инвесторның гамәлләре алгоритмнарын («клиент юлларын»), Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм күрсәтү системасы («Төбәк инвестиция стандарты») турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 591 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъекты инвестиция кагыйдәләре тупланмасын куллануга кертү буенча методик тәкъдимнәр нигезләмәләрен исәпкә алып, ел саен актуальләштерүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасында инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары белән кара-каршы элемтә механизмы булдыру тәртибен эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга тапшырырга;

инвестиция проектын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының Инвестиция советы тарафыннан каралган чаралар планын («юл картасын») эшләү һәм раслау тәртибен билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2012 елның 3 ноябрендәге ПУ-914 номерлы, 2013 елның 20 мартындагы ПУ-242 номерлы, 2013 елның 29 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2013 елның 8 августындагы ПУ-717 номерлы, 2014 елның 29 апрелендәге ПУ-440 номерлы, 2014 елның 27 августындагы ПУ-826 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-984 номерлы, 29 июнендәге ПУ-553 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2018 елның 4 сентябрендәге ПУ-612 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-90 номерлы, 2019 елның 12 октябрендәге ПУ-619 номерлы, 2020 елның 28 мартындагы ПУ-206 номерлы, 2020 елның 26 ноябрендәге ПУ-782 номерлы һәм 2021 елның 23 декабрендәге ПУ-990 номерлы, 2022 елның 11 августындагы ПУ-542 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 13 мартындагы 150 номерлы, 2023 елның 9 сентябрендәге 631 номерлы һәм 2023 елның 28 ноябрендәге 813 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Инвестиция советы турында нигезләмәнең 3 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвестиция проектларын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруның максатка ярашлы булуын һәм аларны Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджетлардан уртак финанслау кирәклеген (мөмкинлеген) карап тикшерү һәм анализлау, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция проекты кураторын билгеләү;»;

б) Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Инвестиция советы) составында:

Инвестиция советы составыннан Ф.Ә. Әгълиуллинны, А.Ю. Егоровны чыгарырга;

Инвестиция советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Габделхаков Рөстәм Рифгать улын – Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе директорын (килешү буенча);

Кадыйров Азат Рифгать улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 14 август
№ 620

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2024 елның « 14 » августындагы
620 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция проекты кураторы турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция проекты кураторын (алга таба тиешенчә – куратор, инвестиция проекты) билгеләү тәртибе, кураторның хокукый хәле һәм аның төп бурычлары билгеләнә.

2. Куратор Татарстан Республикасы Инвестиция советы карары нигезендә республиканың башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре яки территорияләрендә инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары арасыннан, әлеге вазыйфаи затлар белән килештереп, билгеләп куела.

3. Кураторның төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы, инвестиция проектын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъекты, инвестиция проектын гамәлгә ашыруда катнашучы башка затлар белән берлектә инвестиция проектын гамәлгә ашыру буенча чаралар планын («юл картасын») эшләү һәм аны Татарстан Республикасы инвестицион үсеш агентлыгына раслау өчен тапшыру;

б) инвестиция проектын гамәлгә ашыруны мониторинглау;

в) Татарстан Республикасы Инвестиция советы секретаренә инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышы турында квартал саен мәгълүмат биреп бару.

4. Инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатында куратор Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы, инвестиция проектын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъекты, инвестиция проектын гамәлгә ашыруда катнашучы башка затлар вәкилләре белән инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында килеп туган бәхәсле хәлләрне хәл итү өчен киңәшмәләр уздыру хокукына ия.

___________